КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 18 декабрь г.Казань № 1269

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу кенәгәләрен (актлар китапларын) электрон формага күчерү эшләрен оештыру турында» 2017 ел, 15 декабрь, 998 нче карары белән расланган Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу кенәгәләрен (актлар китапларын) электрон формага күчерү эшләрен оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу кенәгәләрен (актлар китапларын) электрон формага күчерү эшләрен оештыру турында» 2017 ел, 15 декабрь, 998 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 10 декабрь, 1102 нче; 2019 ел, 15 апрель, 292 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасында граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алу кенәгәләрен (актлар китапларын) электрон формага күчерү эшләрен оештыру буенча ведомствоара эшче төркем составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

эшче төркем составыннан Р.А.Шәйхетдиновны, А.Р.Мөгыйновны, Ф.В.Гыйлемхановны чыгарырга;

эшче төркем составына түбәндәгеләрне кертергә:

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры Айрат Ринат улы Хәйруллинны;

Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министры урынбасары Радик Расыйх улы Гыйсмәтовны;

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитетының Граждан хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы Римма Шамил кызы Миңнуллинаны (килешү буенча).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин